Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Сөләй авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

05 ноябрь 2019 ел

N 5

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Сөләй авыл җирлегенең
Сөләй авылында гражданнарның
үзара салым акчаларын кертү һәм алардан
файдалану мәсьәләсе буенча
халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 22 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Әлмәт районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылындагы Совет урамы № 1-34 йортларында, Октябрь урамында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 1 нче йорт.

2. 2019 елның 23 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Әлмәт районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылындагы 8 Март, Ветеран урамнарында, Совет урамынын № 35-105 йортларында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл культура йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 60б йорты.

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү челтәрләрен норматив хәлгә китерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең Сөләй авылында сайлау хокукына ия булган авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

5. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авылы башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Сөләй авылы, Совет урамы, 53а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

7. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Сөләй авыл
җирлеге башлыгы А.З. Бикбаев